МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 21/0

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«06» 02 2017

Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган инвалидларның торак биналарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм аның эшләү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 12 һәм 15 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йортта торак биналарны һәм гомуми мөлкәтне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чаралары хакында" 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче торак биналарга карата инвалидларның торак биналарын инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чараларын координацияләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органын билгеләү хакында" 2016 елның 20 декабрендәге 958 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган инвалидларның торак биналарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм аның эшләү тәртибен расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага әлеге боерыкның "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында

урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.М. Фроловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының
2017 елның "06" 02
№21/о боерыгы белән
расланды

# Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган инвалидларның торак биналарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү һәм аның эшләү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган инвалидларның торак биналарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне аларны инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм инвалидлар өчен аларның үтемле булу шартларын тәэмин итү максатларында тикшерү (алга таба – тикшерү) муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган инвалидларның торак биналарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия (алга таба – муниципаль комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.2. Муниципаль комиссия тикшерүне Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йортта торак биналарны һәм гомуми мөлкәтне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чаралары хакында" 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары белән расланган таләпләргә яраклы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче торак биналарга карата инвалидларның торак биналарын инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чараларын координацияләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органын билгеләү хакында" 2016 елның 20 декабрендәге 958 номерлы карары белән расланган чаралар планы (алга таба – чаралар планы) нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Муниципаль комиссия составы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге хакимиятенең норматив-хокукый акты белән раслана.

Муниципаль комиссия составына түбәндәгеләрнең вәкилләре кертелә:

а) муниципаль торак контрольлеге органнары;

б) җирле үзидарә органнары, шул исәптән халыкны социаль яклау өлкәсендә, архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә;

в) инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре.

Инвалидның торак бинасы урнашкан, аңа карата тикшерү үткәрелә торган күпфатирлы йорт белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма вәкилләре муниципаль комиссия эшендә катнашуга җәлеп ителергә мөмкин.

## 2. Муниципаль комиссиянең эшләү тәртибе

2.1. Муниципаль комиссия эшчәнлеген оештыру-техника ягыннан тәэмин итүне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

2.2. Комиссия утырышлары зарурлык булу дәрәҗәсенә карап, ләкин өч айга бер мәртәбәдән артмаган ешлыкта үткәрелә.

2.3. Муниципаль комиссия рәисе муниципаль комиссия эше белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, муниципаль комиссия утырышларын үткәрә. Муниципаль комиссия рәисе булмый торган очракта утырышны муниципаль комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

2.4. Муниципаль комиссия әгъзалары:

– муниципаль комиссия эшендә катнаша, документларны өйрәнә, алар буенча кисәтүләр, тәкъдимнәр, ризасызлыклар әзерли;

– муниципаль комиссия утырышларында катнаша, ә муниципаль комиссия утырышында катнашу мөмкинлеге булмаган очракта муниципаль комиссия сәркатибенә карап тикшерелүче мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язмача рәвештә алдан ук җиткерә, ул утырышта игълан ителә һәм муниципаль комиссия бәяләмәсенә теркәлә.

Муниципаль комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен бүтән затларга тапшырырга хокуклы түгел.

2.5. Муниципаль комиссия сәркатибе:

– муниципаль комиссия утырышларын үткәрүне оештыра;

– муниципаль комиссия әгъзаларына һәм муниципаль комиссия эшендә катнашуга җәлеп ителгән затларга утырышның көн тәртибе, датасы һәм аны үткәрү урыны хакында утырышка кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча мәгълүмат ирештерә;

– муниципаль комиссиянең эш кәгазьләрен алып бара.

2.6. Муниципаль комиссия утырышы, әгәр дә анда аның әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы булып санала.

2.7. Муниципаль комиссия карарлары муниципаль комиссия әгъзаларының күпчелек тавышлары нигезендә кабул ителә. Муниципаль комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, муниципаль комиссия рәисенең тавышы хәл иткеч була. Кабул ителгән карар белән ризалашмаган очракта муниципаль комиссия әгъзалары үзләренең махсус фикерен язмача рәвештә чагылдырырга һәм аны муниципаль комиссия карарына теркәргә хокуклы.

2.8. Муниципаль комиссия тикшерүе нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланучы рәвештә, инвалидның торак бинасын һәм инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне аларны инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм инвалид өчен аларның үтемле булу шартларын тәэмин итү максатларында тикшерү акты (алга таба – Тикшерү акты) рәсмиләштерелә.

2.9. Әгәр дә Тикшерү актында инвалидның торак бинасын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне инвалидның

ихтыяҗларын һәм инвалид өчен аларның үтемле булу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып яраклаштыру өчен техник мөмкинлекнең булмавы хакында, ягъни. күпфатирлы йортның (йортның бер өлешендәге) гамәлдәге терәк һәм киртә конструкцияләрен аны үзгәртеп коруны яки капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыру юлы белән үзгәртмичә, инвалидның торак бинасын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен аларның үтемле булу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып яраклаштырып булмавы хакында нәтиҗә булса, муниципаль комиссия инвалидның торак бинасын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен аларның үтемле булу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып яраклаштыру максатларында күпфатирлы йортта (йортның бер өлешендә) мондый үзгәртеп коруның яки капиталь ремонтлауның икътисадый яктан максатка ярашлы булуына карата тикшерү үткәрү хакында карар чыгара.

2.10. Инвалидның торак бинасын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен аларның үтемле булу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып яраклаштыру максатларында күпфатирлы йортта (йортның бер өлешендә) мондый үзгәртеп коруның яки капиталь ремонтлауның икътисадый яктан максатка ярашлы булуын (максатка ярашлы булмавын) тикшерү нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланучы рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Торак биналарны һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чаралары хакында" 2016 елның 09 июлендәге 649 номерлы карары белән расланган Инвалидлар өчен торак биналарның һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең үтемле булу шартларын тәэмин итү кагыйдәләренең 17 пунктында каралган карарларның берсен кабул итә.

2.11. Инвалидның торак бинасын һәм инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен аларның үтемле булу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып яраклаштыру мөмкинлеге турында бәяләмә яки мондый мөмкинлекнең булмавы турында бәяләмә муниципаль комиссия эшенең нәтиҗәсе була.